РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ТЕТЮШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422370 г.Тетюши, ул.Малкина, 39

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТӘТЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
422370 Тәтеш шәһәре, Малкин ур, 39

тел. (84373) 2-50-02, 2-53-33, факс 2-62-48, e-mail: tatesh@tatar.ru
ОКПО 78702097, ОГРН 1061672000037, ИНН/КПП 1638004978/163801001

# КАРАР

**2020 ел 1 июнь** **№ 51-16**

**Тәтеш муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы 2017 елның 20 мартындагы 21-4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясе Хезмәт кодексына хезмәт эшчәнлеге турындагы мәгълүматларны электрон рәвештә формалаштыру өлешенә үзгәрешләр кертү турында»гы 2019 елның 16 декабрендәге 439-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Тәтеш муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы 2017 елның 20 мартындагы 21-4 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турында нигезләмәнең 8 өлешендәге 5 абзацында «хезмәт кенәгәсе» сүзтезмәсеннән соң «һәм (яки) хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Тәтеш муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе А.А. Гасимовка йөкләргә.

**Татарстан Республикасы**
**Тәтеш муниципаль районы башлыгы** **Р.Х. Сафиуллов**